СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район
с.Алан-Бексер, ул.Центральная, д.19

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**01 ноябрь 2023ел** **№ 85**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 2019 елның 18 ноябрендәге 194 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында" 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 18 ноябрендәге 194 номерлы карарына (Советның 19.05.2020 елгы 217 номерлы, 16.11.2022 елгы 64 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның 1 нче пунктчасы 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“ - торак фонды һәм (яисә) торак - коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары (күчемсез милек объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган җир участогы өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (сатып алынган (бирелгән) җир участокларыннан тыш) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен);".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының интернет челтәрендәге http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча урнашкан рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина